# Халкыбызның күңел җәүһәрләре



Әбиебез сандыгында
Сакланмый ниләр генә.
Әйдәгез сорыйк үзеннән,
Ачып күрсәтсен безгә.

Каян аңлап алды икән
Әби безнең теләкне? —
Түрдә торган сандыгын ул
Үзе ачып күрсәтте.



Әби ничек матур итеп
Киенгән яшь чагында...
— Бу бит минем туй күлмәгем,
Бабаеңа чыкканда.

Күкрәктә изү-бизәге,
Әллә бабай бүләге?
Диңгез суы кебек тора —
Дулкынлана итәге.





